**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы**
**Дүрт-Мунча авыл җирлеге Советы**

# КАРАРЫ

**№ 26** **08.02.2021ел**

**«Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Дүрт-Мунча авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмә хакында» 2014 елның 05 февралендәге 129 номерлы Зәй муниципаль районы Дүрт-Мунча авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән расланган «Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы» нигезендә, Зәй муниципаль районының Дүрт-Мунча авыл җирлеге Уставына таянып, Зәй муниципаль районының Дүрт-Мунча авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Дүрт-Мунча авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмә хакында» 2014 елның 05 февралендәге 129 номерлы Зәй муниципаль районының Дүрт-Мунча авыл җирлеге Советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 9 статьяның 22 өлешендә «хезмәт кенәгәсен» сүзләреннән соң «(булган очракта)» дигән сүзләрне өстәргә;

1.2. 15 статьяның 4 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. «4. Җирле үзидарә органы, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппараты җитәкчесе булган муниципаль хезмәткәр, әлеге муниципаль хезмәткәрнең урынбасары, мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау максатларында, әлеге җирле үзидарәнең сайланулы профсоюз органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында тиешле вазыйфаны биләгән чорда муниципаль хезмәткәрләрнең мәнфәгатьләрен чагылдыра (тәкъдим итә) алмый.»;

1.3. 29 статьяда:

а) 10 өлешнең 2 пунктында «хезмәт кенәгәсенең күчермәсе» сүзләрен «законнарда билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән хезмәт эшчәнлеге турында белешмәләр һәм (яисә) хезмәт кенәгәсенең күчермәсе» сүзләренә алмаштырырга;

б) түбәндәге эчтәлекле 19.1 өлешне өстәргә:

«19.1. Муниципаль хезмәт вазыйфасын биләгән затка тиешле еллар

эшләгән өчен пенсия Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычлары булмаганда билгеләнә.

Тиешле еллар эшләгән өчен пенсия билгеләүне сорап мөрәҗәгать иткәннән соң 90 көн эчендә бурыч түләү җайга салынганда, тиешле еллар эшләгән өчен пенсия билгеләү шундый билгеләүне сорап мөрәҗәгать иткән көннән башкарыла.»;

1.4. 31 статьяда:

а) 2 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Муниципаль хезмәт стажын раслый торган төп документлар булып билгеләнгән үрнәктәге хезмәт кенәгәсе һәм (яки) законнарда билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән хезмәт эшчәнлеге турында белешмәләр тора.»;

б) 4 өлештә «хезмәт кенәгәсенә» сүзләреннән соң «һәм (яки) законнарда билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән хезмәт эшчәнлеге турында мәгълүматлар» сүзләрен өстәргә;

1.5. 35.1 статьяның 8 өлеше 4 пунктында «хезмәт кенәгәсенең күчермәсен» сүзләрен «законнарда билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән хезмәт эшчәнлеге турында мәгълүматлар һәм (яки) хезмәт кенәгәсе күчермәсен» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU), җирлек торак пунктлары территориясендәге махсус мәгълүмат стендларында һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

**Совет рәисе,**
**авыл җирлеге башлыгы** **Р.Т.Ситдиков**